Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2025 елның 12 марты №133

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында 2017 елның 30 маендагы 41 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының 2025 елның 31 гыйнварындагы Прдп-20-25 номерлы прокуратурасы протесты һәм «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм хайваннарны индивидуаль яисә төркемләп маркировкалау һәм исәпкә алу очракларын, шулай ук хайваннарны исәпкә алу срокларын гамәлгә ашыру очракларын, индивидуаль яисә төркемләп маркировкалау һәм исәпкә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 5 апрелендәге 550 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 2017 елның 30 маендагы 41 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба-кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Кагыйдәләрнең 185 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк,4 ур. (Мәдәният йорты бинасы);

- ТР, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16 йорт (кибет бинасы)

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,
Тамагы муниципаль районының
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе Э.И.Байдамшин